СОВЕТ КЛЯУШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Первомайская, д.51, д.Пойкино,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422142

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЕЛӘҮШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Беренче май ур., 51 нче йорт, Пойкино авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422142

тел.(факс): (85563) 3-89-193; e-mail: Kls.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Карар　　　　　　　　　　　　　　　　Решение
«10» гыйнвар 2025 ел.　　　　　　　　　　№ 3-42

**Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлеге башлыгы, Совет рәисе вазыйфаларын йөкләү турында**

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлеге башлыгы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылу сәбәпле, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 36 статьясының 7 өлеше, Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 46 статьясындагы 4 өлеше нигезендә, Келәүш авыл җирлеге Советы Регламентының 14 статьясындагы 3 пунктына таянып, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлеге Советы к а р а р к а б у л и т т е:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлеге башлыгы вазифаларын 2025 елның 10 гыйнварыннән Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлеге башлыгы урынбасары, 6 нче номерлы Келәүш бермандатлы сайлау округы буенча депутат Шайдуллин Руслан Халимовичка йөкләргә.

2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлеге Башлыгы вазыйфаларын башкаручыга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлеге Советы рәисе вәкаләтләрен, башкаруга керешергә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Келәүш авыл җирлеге башлыгы вазыйфаларын башкару чорында Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Келәүш башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфаларын башкарырга керешергә.

3. Карар кабул ителгән көннән үз көченә керә.

4.Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://mamadysh.tatarstan.ru веб-адресы буенча Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Келәүш авыл җирлеге торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Утырышта рәислек итүче　　　　　　　　Р.Х.Шайдуллин

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «КЛЯУШСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
СОВЕТ КЛЯУШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ